**КАЗАН ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**

**Казан шәһәре хакимиятенең мәгариф идарәсе Совет районы “Дәрвишләр бистәсенең балалар иҗаты үзәге” өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе**

| **«КАБУЛ ИТЕЛДЕ»**<br>ӨБМБУ “Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәге” методик киңәшмәсендә<br><br>Беркетмә №_1____________<br><br>« 29 » 08. 2022 ел. | **«РАСЛЫЙМ»**<br>«Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәге» директоры<br>____________ Гомәрова Ф.М.<br><br>Боерык №_ 32-ОД<br>«29» 08.2022ел. |
|---|---|

# Социаль-гуманитар юнәлештәге «Туган тел» берләшмәсенең өстәмә гомумбеле бирү һәм гомумүстерү программасы

## программа 4 елга исәпләнгән 7-11 яшьлек балалар өчен


**Төзүче автор:**
**югары квалификацион категорияле өстәмә белем бирү педагогы**
**Шиһабиева Әдилә Халик кызы**


**Казан, 2022 ел.**

## Информационная карта образовательной программы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | **Образовательная организация** | Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр детского творчества пос. Дербышки» Советского района г. Казани |
| 2. | **Полное название программы** | Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Туган тел» |
| 3. | **Направленность программы** | Социально-гуманитарная |
| 4. | **Сведения о разработчиках** | |
| 4.1. | ФИО, должность | Шигабиева Адиля Халиковна<br>педагог дополнительного образования |
| 5. | **Сведения о программе:** | |
| 5.1. | Срок реализации | 4 года |
| 5.2. | Возраст обучающихся | 7 - 11 лет |
| 5.3 | Характеристика программы:<br>- тип программы<br><br>- вид программы<br>- принцип проектирования программы<br>- форма организации содержания и учебного процесса | дополнительная общеобразовательная программа<br>общеразвивающая<br>разноуровневая |
| 5.4. | Цель программы | Создание условий для раскрытия творческих способностей личности учащихся начальных классов. |
| 5.5. | Образовательные модули (в соответствии с уровнями сложности содержания и материала программы) | Стартовый уровень<br>Базовый уровень |
| 6. | **Формы и методы образовательной деятельности** | **Формы:** интегрированные занятия, исследование, литературная гостиная, круглый стол, заочная экскурсия<br>**Методы:** словесные, наглядные, практические, исследовательские |
| 7. | **Формы мониторинга результативности** | Беседа, опрос, практические задания, тестирование, исследовательский проект, участие в конкурсах |
| 8. | **Результативность реализации программы** | Входная и текущая диагностика, промежуточная аттестация обучающихся. Аттестация по завершении освоения программы. Участие в конкурсах различного уровня:<br>- Республиканский эпистолярный конкурс "Письмо писателю любимой книги"- Мингалиева А. диплом участника, 2020<br>- Республиканский конкурс "Нобелевские надежды КНИТУ-2021" – Хабибуллина А., 3 место, 2021.<br>- Межрегиональная научно-исследовательскя конференция имени Р.Миннуллина – Шигабиев |

| | | |
|---|---|---|
| | | И., 2 место, 2021. |
| 9. | **Дата утверждения и последней корректировки программы** | Протокол педагогического совета ЦДТ №1 от 29.08.2022<br>Приказ директора № 32-ОД от 29.08.2022<br>Изменения, внесенные в программу в 2022-2023 уч.году:<br>- изменения в нормативно-правовой базе<br>- корректировка целей и задач<br>- изменения в мониторинге качества освоения программы |
| 10. | **Рецензии:**<br>**Внутренняя экспертиза** | Хафизова Т.Л., методист ЦДТ пос. Дербышки |

# Эчтәлек

**Комплекс основных характеристик программы:**

1. Аңлатма язуы………………………………………...........................................……………… 5 б.
2. Белем бирү программасының матрицасы …….................………………………….....……10 б.
3. Беренче уку елына укыту планы……………….................…………………………..13 б.
4. Беренче уку елы программасының эчтәлеге.......................................................................14 б.
5. Икенче уку елына укыту планы …………………….................………………………15 б.
6. Икенче уку елы программасының эчтәлеге ………….................…………………………..17 б.
7. Өченче уку елына укыту планы ……………………................……………………17 б.
8. Өченче уку елы программасының эчтәлеге …………….............………………………19 б.
9. Дүртенче уку елына укыту планы ………………………...............……………………19 б.
10.Дүртенче уку елы программасының эчтәлеге …………….........………………………21 б.

**Комплекс организационно-педагогических условий:**

11. Программаны үтәүдә педагогик-оештыру шартлары ……...........................................…..22 б.
12. Аттестация/контроль формасы һәм бәяләү материалы..………………...............……..22 б.
13.Әдәбият исемлеге..................................................................................................................22 б.

**Кушымталар:**

Кушымта 1. Беренче уку елының календарь-укыту графигы…………..........................…24 б.
Икенче уку елының календарь-укыту графигы...........................................28 б.
Өченче уку елының календарь-укыту графигы ……….......................……34 б.
Дүртенче уку елының календарь-укыту графигы ....................................... 40 б.
Кушымта 2. Мониторинг качества освоения образовательной программы..........................47 б.
Кушымта 3. Диагностические и оценочные материалы……………………....................... 51 б.

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Туган тел” берләшмәсе программасы укучыларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү максатыннан чыгып төзелә. 7-11 яшьтәге укучыларга исәпләнелә. Бу программа Н.А.Спиринаның “Журналистика в школе” дигән программасына нигезләнеп төзелде. Өстәмә белем бирү системасында уку планының вариатив өлеше буларак тормышка ашырыла.

**Программаны эшләүдә кулланылган төп норматив документлар:**

- Федеральный закон РФ 273-ФЭ «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 г.
- Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 09 ноября 2018 N 196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам».
- Приказ Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 5 мая 2018 г. N 298 «Об утверждении профессионального стандарта "Педагог дополнительного образования детей и взрослых».
- Стратегия инновационного развития Российской Федерации на период до 2020 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 8 декабря 2011 г. № 2227-р.
- Федеральная целевая программа развития образования на 2016-2020 годы, утвержденная Постановлением Правительства Российской Федерации от 23 мая 2015 г. № 497.
- Концепция развития дополнительного образования детей до 2030 года. Утверждена распоряжением Правительства Российской Федерации от 31 марта 2022 г. № 678-р.
- Стратегическая инициатива "Новая модель системы дополнительного образования", одобренная Президентом Российской Федерации 27 мая 2015 г.
- Санитарно-эпидемиологические требования к организации воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи - СП 2.4.3648-20 от 1.01.2021г (Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.09.2020 №28).

-Устав МБУДО «Центр детского творчества пос.Дербышки» Советского района г. Казани.
-Положение о дополнительных общеобразовательных общеразвивающих программах

Укучыларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә, ашыкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, сөйләм телен үстерү юнәлешендә даими эш алып барылырга тиеш. Ә бу максатларны тормышка ашыруда нәфис сүз, әдәби әсәрләр, милли матбугат һәм халык авыз иҗаты әсәрләренең әһәмияте гаять зур. Алар укучыларны логик фикер йөртүләрен үстерә, дөньяны танып белергә өйрәтә, әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүгә булышлык итә.

Программа өчен материал туплаганда, иң элек әсәрнең баланы ни дәрәҗәдә кызыксындыра алуы (үзенең эчтәлеге белән балага якын булуы), сөйләм телен баетуга ярдәме, тәрбияви әһәмияте искә алынды. Шулай ук балаларның психологик үсеше һәм яшь үзенчәлекләренә зур игътибар бирелде.

Белем һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеге балаларда укуга кызыксындыру уятуга бәйле. Укытуның төп формасы – дәрес. Ләкин дәрес кысаларында гына телнең матурлыгын, байлыгын, тирәнлеген күрсәтү өчен мөмкинлекләр чикләнгән. Чөнки, беренчедән, уку дәресләренә, бигрәк тә башлангыч сыйныфта, бик аз сәгатьләр бирелә. Икенчедән, программа материалыннан тыш та хәзинәгә тиңләрлек әсәрләребез бик күп, аларның барысын да мәктәп программасына кертеп бетерү мөмкин түгел. “Туган тел” берләшмәсе программасының ***актуальлеге*** шулар белән аңлатыла.

“Туган тел” берләшмәсе дәрестән тыш эшчәнлекнең бер юнәлеше буларак тәкъдим ителә. Программа эчтәлеге һәм укыту методлары буенча укучыларның дәресләрдә алган белем-күнекмәләрен тулыландыру, укуга кызыксыну тәрбияләү, укыту һәм тәрбиянең бергәлеген ныгытуда зур роль уйный.

Балаларның кече яшьтән үк татар халык иҗатын, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнүе дә игътибарга лаек. Шул ук вакытта балаларның сөйләм телен үстерү дә мөһим бурычларның берсе булып тора.

**Максат:** укучыларда татар теленең күп мәдәниятле мохиттәге роле һәм әһәмияте турында беренчел күзаллау формалаштыру; аларда татар халык иҗатына, мәдәниятенә, матбугатына һәм әдәбиятына ихтирам хисе тәрбияләү, ватанпәрвәрлек хисе уяту, иҗади сәләтләрен арттыру.

**Программаның бурычлары**

***Белем бирү бурычы:***

- ✓ укучыларда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту;
- ✓ укучыларның иҗади шәхес буларак формалашуына булышу;
- ✓ әдәби әсәрләрне дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру,
- ✓ татар халык авыз иҗаты әсәрләренең төрләрен аера белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллану;
- ✓ текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәтү;
- ✓ әсәрнең тел-бизәкләү, сурәтләү чараларын табу, анализлау күнекмәләрен үстерү; темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;
- ✓ милли матбугат белән кызыксындыру, укучыларга матбугат жанрлары, төрләре буенча башлангыч белем бирү;

***Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү бурычы:***

- ✓ Укучыларның иҗади сәләтләрен төрле яклап үстерү, гомуми күзаллауларын киңәйтү.
- ✓ Әдәби иҗатка, матбугатка кагылышлы теоретик белемнәрне тирәнәйтү, анализлау, башлангыч күнекмәләр булдыру һәм аларны гамәли яктан тормышта дөрес кулланырга өйрәтү.
- ✓ Халык авыз иҗаты әсәрләрен анализлау; тел бизәкләү, сурәтләү чараларын кулланып, төрле жанрда иҗат итү; алынган тема буенча телдән чыгыш ясый белү, язу күнекмәләрен булдыру.

*Программаның тәрбияви бурычы:*

- ✓ Үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
- ✓ Төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисе тәрбияләү.
- ✓ Үз-үзеңне тоту һәм сөйләм культурасы тәрбияләү.
- ✓ Туган телен, матбугатын, мәдәниятен белгән камил шәхес тәрбияләү.

*Берләшмә эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнә:*

- кызыксындыручанлык;
- фәннилек;
- аңлаешлылык;
- күрсәтмәлелек;
- теориянең практика белән тыгыз бәйләнеше;
- аңлы һәм актив эшчәнлек;
- һәр укучыга шәхси якын килү.

“Туган тел” берләшмәсе эшчәнлеге һәр укучының яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләү өчен, зур мөмкинлекләр тудыра.

*Үткәрү формалары:*

- әңгәмә;
- халык аваз иҗаты әсәрләре белән (табышмак, мәкаль, санамыш, такмак, әйтенүләр, эндәшләр, алдавыч әкиятләр, тел төзәткечләр, мәзәкләр), уеннар, кроссворд, ребус, башваткычлар белән практик эш;
- төрле типтагы текстларны уку һәм анализлау;
- мөстәкыйль, иҗади эшләр, рольле уеннар;
- иҗади остаханә, әдәби кунакханә, түгәрәк өтәл, кулъязма (компьютерда) газета чыгару.

Утырышлар иҗади эш элементлары белән җанландырыла: мөстәкыйль рәвештә кроссворд, ребус, башваткычлар төзү; төрле жанрда иҗат итү күнекмәләре булдыру, газета-журналга мәкаләләр язу, халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәгендә иҗади эшчәнлеккә тарту.

***Һәр шөгыль өч өлештән тора: теория өлеше, практик өлеш һәм уен.***

*Төп метод һәм технологияләр*

- ✓ үстерелешле укыту технологиясе;
- ✓ хезмәттәшлектә укыту технологиясе;
- ✓ коммуникатив технология;
- ✓ индивидуаль якын килү технологиясе.

***Планлаштырылган нәтиҗәләр***

1. **Шәхси-үзгәреш нәтиҗәләре:**
   - ✓ гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш-гамәлләрен, тормыш ситуацияләрен бәяләү;
   - ✓ текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү;
   - ✓ башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү;
   - ✓ Укылган әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.
2. **Предметара нәтиҗәләр:**

*Шәхси универсаль уку гамәлләре*

1. Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык, түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.
2. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.
3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү.

I. *Регулятив универсаль уку гамәлләре:*

1. Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оешытру.
2. Укытучы җитәкчелегендә дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.

II. *Танып-белү универсаль уку гамәлләре:*

1. Китап, вакытлы матбугат белән эшләү.
2. Төрле чыганаклардан тиешле мәгълүматны табу.
3. Әдәби әсәрләрдәге, халык авыз иҗаты үрнәкләрендәге геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу.
4. Укылган яки тыңланган текстның тел үзенчәлекләрен анализлау, сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйләү.

III. *Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:*

1. Дәрестән тыш эшчәнлектә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.
2. Иҗади биремнәргә, сорауларга җавап бирү.
3. Сөйләм этикеты нормаларын үтәү.
4. Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.
5. Парлап һәм төркемнәрдә иҗади эшләү.

**Предмет нәтиҗәләре**

1. Укылган текстны ишетеп аңлау.
2. Бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку.
3. Текстны тулысынча сөйләү.
4. Табышмак, мәкаль, санамыш, такмак, әйтенүләр, эндәшләр, тел төзәткечләрне ятлау.
5. Рәсем буенча телдән хикәя төзү.
6. Халык авыз иҗаты жанрларын аера белү.
7. Балалар матбугаты белән даими танышу, төрле жанрда иҗат итү.

Дүрт ел дәвамында укучылар үз ана телендә иркен аралашырга, иҗат итәргә өйрәнәләр, әдәби иҗатка тартылалар.

“Туган тел” берләшмәсенә йөрүче укучыларның төрле дәрәҗәдәге конкурсларда актив катнашулары, газета-журналларга даими язышулары, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашулары планлаштырыла.

Утырышлар беренче уку елында төркемнәрдә атнасына ике тапкыр икешәр сәгать уздырыла.

***Төркемнәрдәге укучылар саны:***

1 нче уку елы – 15 бала
2 уку елы – 15 бала
3 уку елы – 15 бала
4 уку елы – 15 бала

***Бер елга сәгатьләр бүленеше:***

***Дүрт елга барлык сәгатьләрсаны: 792 сәгать***

1 нче уку елы – 144 сәг.

***2 нче - 4 нче уку елы*** – атнага 6 сәгать исәбеннән (216 сәгать)

***Программа үз эченә түбәндәге белем һәм күнекмәләрне ала:***

***Белем бирү***: иҗат итүнең төрле тармаклары белән танышу, балалар матбугатын, жанр төрлелеген, яшь хәбәрчегә куелган таләпләрне өйрәтү;

***Алган белемнәрне гамәли куллану***: балалар матбугаты белән даими кызыксыну, төрле жанрда иҗади эшләрне хисси кабул итә белү, хәрәкәтле уеннар, җырлы-биюле уеннар өйрәнү, иҗатның төрле тармаклары буенча иҗади эшләр башкару;

***Тәрбияви:*** татар матбугаты, әдәбияты, сәнгате үрнәгендә әхлак тәрбиясе бирү, коллективта күмәк эшләү, иҗат итү күнекмәләрен үстерү, иҗади фикер йөртүче, компетентлы шәхес тәрбияләү.

## МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

«Туган тел» дип аталган бу программада һәр бүлекне өйрәнгәннән соң рольле уеннар, иҗади эшләр һәм телдән хәбәрләр формасында контроль эшләр һәм зачетлар үткәрү планлаштырыла.

Уку-укыту материалының тупланышы аны эзлекле өйрәнү һәм вариатив куллану мөмкинлеген тәэмин итә. Һәм моны укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, аларның яшь үзенчәлекләрен, региональ һәм милли үзгәлекләрне исәпкә алып, педагог үзе эшли.

Әлеге программаның мөһим компоненты булып милли-төбәк компоненты тора. Берләшмә утырышларына үз шәһәрең, Дәрвишләр бистәсе, эти-әнисенең туганягы турында да культурологик материал кертү мөһим; шулай ук балаларда гаиләдәге гореф-гадәтләр, мәшһүр якташлар, туган төбәкнең мәдәни мирасына сакчыл караш тәрбияләргә дә өйрәтергә кирәк.

Дәрвишләр бистәсендә укучыларны иҗади үстерү өчен табигый, икътисади, фәнни һәм мәдәни байлыклар күп. С.Галиев исемендәге мәдәният сарае, Хезмәт һәм дан музее, китапханәләр челтәре, заманча җиһазландырылган уку залы.

Шуның белән беррәттән төрле елларда Дәрвишләр бистәсендә яшәгән күренекле шәхесләр иҗатын өйрәнү, барлау, туплау да күз уңында тотыла.

Иҗади эшчәнлеккә тарту укытучыдан бай иҗади лаборатория, күптөрле дидактик материал таләп итә. Балалар матбугатының тупланмасы, электрон вариантын куллану укучыларны пассив тыңлаучылар гына түгел, ә актив иҗатчылар итеп тәрбияләүгә ярдәм итә.

Материалың үзләштерү дәрәҗәсенең төп күрсәткечләре тупланган белемнәр генә түгел, укучыларның иҗади фикерләве, башкаларның иҗатына дөрес итеп бәя бирүләре, үз карашын нигезләп аңлата белүләре, аудитория каршында яклый алулары, булган белемнәрен гамәлдә куллана белүләреннән гыйбарәт. Укучыларның белем дәрәҗәсен ачыклау өчен, дискуссия, тикшеренү проектлары, иҗади эшләр конкурслары кебек чаралар да оештырырга мөмкин.

Материалын үзләштергәннән соң, йомгаклау дәресе булырга тиеш. Һәр темада дәресләр саны якынча бирелгән һәм, балаларның әзерлекләре дәрәҗәсен исәпкә алып, үзгәртелергә дә мөмкин.

җатка тарту, милли матбугат белән мавыктыру.

## Программа буенча буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү

Программа буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү берничә этапта башкарыла: гадәти, яртыеллык, йомгаклау,

Гадәти (агымдагы) контроль берләшмә утырышларында һәр укучының эшчәнлеген, иҗади үсешен күзәтү, юнәлеш бирү, аның нәтиҗәләрен анализлау формасында уздырыла.

Яртыеллык контроль билгеле бер темаларны узгач, тестлар формасында уздырыла.

Йомгаклау тикшерүе һәр уку елы азагында иҗади остаханә, әдәби кичә, шигъри сабантуй, кызыклы очрашулар клубы һ.б. формаларда берләшмәнең ачык утырышы итеп уздырыла.

***Белем бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре*** : укучыларның туган телдә камил сөйләшүе, халык авыз иҗаты үрнәкләрен, иҗади осталык серләрен белүе, иҗат итүгә омтылыш уяну.

***Укучыларның белем-күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәләре өч төрдә бәяләнә:***

Югары

Уртача

Түбән

**Бу программаның үзенчәлеге шунда** – ул әзерлек дәрәҗәләре, белемнәре, мөмкинлекләре төрле булган балаларның мәнфәгатьләрен истә тотып төзелгән**.**

Программаны төзегәндә төрле дәрәҗәдәге критерияләр

- төрле катлаулылыкта булган укыту материалын эченә алган үз матрицасы бар;
- төрле катлаулылыкта булган укыту материалы методик яктан каралган;
- берләшмәгә йөрче һәр укучының төрле катлаулылыктагы биремнәрне үтәү мөмкинлеге бар;
- укучыларның белем һәм күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү матераллары да төрле яссылыкта бирелгән

## БЕРЕНЧЕ УКУ ЕЛЫ

Башлангыч этапта төп **бурыч** укучыны туган тел аша матбугат һәм әдәбият дөньясына алып керү, аларны иҗади мавыктыру, иҗади эшчәнлеккә кызыксыну уяту, “Туган тел” берләшмәсенең утырышларына йөрүгә ихтыяҗ тудыру. Шуңа күрә дә белем бирү беренче елдан ук мавыктыргыч, укучыларны кызыксындырырдай булырга тиеш.

**Беренче ел азагында укучылар белергә тиеш:**

- Яшь хәбәрчегә куелган таләпләр
- Халык авыз иҗаты әсәрләренең төрләре
- Иҗат итү күнекмәләре
- Аудитория каршында чыгыш ясау
- Үз фикереңне дәлилли белү
- Әдәби туган як, тарихи һәйкәлләр, истәлекле урыннар
- Үзе яшәгән төбәкнең мәдәни тормышында булган әһәмиятле вакыйгалардан хәбәрдар булу

**Беренче ел азагында берләшмәдә тәрбияләнүчеләр алган белем һәм күнекмәләр:**

- Туган як фольклоры, тарихыннан хәбәрдар булу
- Укыган әсәргә бәя бирә белү, анализ ясау
- Текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү
- Башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү
- Укылган мәкаль, әкият геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.
- Иҗат итү күнекмәләре булдыру

**Беренче ел азагында берләшмәгә йөрүчеләрдә тәрбияләнергә тиешле сыйфатлар:**

- Яшь хәбәрчегә куелган сыйфатларны булдырырга омтылыш
- Әхлакый кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү
- Иҗади эшчәнлеккә карата кызыксыну формалаштыру.
- Тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү.
- Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оешытру.
- Укытучы җитәкчелегендә дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.
- Дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү планын билгеләү.

### Беренче уку елына укыту-тематик планы

| Т/п № | Тема | Сәгәть саны | Теория | Практика | Формы организации занятий | Контроль/ аттестация формалары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1.** | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш педагогик-психологик диагностика | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Әңгәмә | Сораштыру<br>Тест<br>Иҗади эш |
| 2. | Яшь хәбәрчегә таләпләр | 18 | 10 | 8 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 3. | Туган як тарихы | 24 | 14 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 4. | Казан – гүзәл башкала | 24 | 14 | 10 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Халык сүзендә хикмәт бар | 28 | 14 | 14 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку<br>Театрлы уен | Әңгәмә<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6. | Әкияттә кунакта | 30 | 15 | 15 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 7. | Иҗади остаханә, очрашулар | 14 | 4 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина<br>Театрлы уен | Әңгәмә<br>Тест<br>Иҗади эш |
| 8. | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 9. | Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| | **Барысы** | **144** | **74** | **70** | | |

## Беренче уку елы программасының эчтәлеге

**1.** Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш педагогик-психологик диагностика

***2. Яшь хәбәрчегә таләпләр***: Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү. Яшь хәбәрчегә хас сыйфатлар. Ул нинди сыйфатларны туплаган булырга тиеш? Хәбәрче өчен иң кирәкле сыйфатлар: кызыксынучанлык, күзәтүчәнлек, белемлелек, төгәллек, өлгерлек. Аларны үзеңдә булдыру.

***3. Туган як тарихы***: Дәрвишләр бистәсе тарихы белән танышу. Сугыш һәм хезмәт ветераннары хакында мәгълүмат туплау, аларга багышлап шигырьләр язу, мәкаләләр иҗат итү.

***4. Казан – гүзәл башкала***: шәһәрнең истәлекле урыннары, театрлар хакында мәгълүмат бирү. Тарихи һәйкәлләр буенча вертуаль сәяхәт итү.

***5. Халык сүзендә хикмәт бар***: халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру, аның төрләрен аера белү, мәгънәләренә төшенү. Балалар өчен нәшер ителүче вакытлы матбугат битләрендәге такмаклар белән танышу. Такмакларга иллюстрация. Үзлектән такмак иҗат итү. Татар халкының такмаклы уеннарын уйнау:"Чума үрдәк, чума каз..", "Кәрия-Зәкәрия". Яңа ай күргәндә, суга чумганда, егылган вакытта әйтенүләр. Уен "Чагыштыруларны тап" ("Кем тизрәк, өлгеррәк", укытучылар, ата-аналар һәм урта педагогик уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы,Мияссарова И.Х., Гарифуллина Ф.Ш., Гильфанова Ә.Ә. – Казан,2010, 75нче бит)

***6. Әкияттә кунакта***: төрле әкиятләрне уку, өйрәнү, сәхнәләштерү, тел сурәтләү чараларын табу. Әкиятләрнең төзелешен, язу үзенчәлекләрен аңлату. Хайваннар турында әкиятләр иҗат итү. Тылсымлы әкиятләр иҗат итү. Тормыш-көнкүреш әкиятләре иҗат итү. Хайваннар турында халык әкиятләре .Кәҗә бәтиләре һәм Бүре. Татар халык әкияте.Кем нәрсә ярата? Татар халык әкияте.Төлке белән Каз. Татар халык әкияте.Көнкүреш әкиятләре.Ялкау малай. Татар халык әкияте.Кәкре каенга терәткән. Татар халык әкияте. Тылсымлы әкиятләр.Зөһрә йолдыз.Ике кыз.Татар халык әкияте. Әкиятләр уку, аларның эчтәлеге буенча эш. Рәсемнәр конкурсы. "Әкияттә кунакта" викторина. Әкиятне рольләргә бүлеп уйнау. Уеннар: "Нарат урманында, бүре янында", "Куянкай", "Мөгезле кәҗә", "Аучы

һәм көтүче”. Пластилиннан әвәләп әкият геройлары ясау. Татарча мультфильмнар карау. Тест “Татар халык әкиятләрен беләсезме? (“Кем тизрәк, өлгеррәк”, укытучылар, ата-аналар һәм урта педагогик уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы,Мияссарова И.Х., Гарифуллина Ф.Ш., Гильфанова Ә.Ә. – Казан,2010, 71нче бит).

*7. Иҗади остаханә, очрашулар*: театрларга сәяхәт, иҗади эшләрне туплап китапчыклар чыгару, очрашуларга әзерлек, аудитория алдында чыгыш ясау күнекмәләре. Туган телдә ирке сөйләшү, фикер алышу, иҗат итү омтылышы уяту.

**8. Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.**

**9. Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация**

## ИКЕНЧЕ УКУ ЕЛЫ

“Туган тел” әдәби-иҗат берләшмәсенең икенче уку елына **максаты:** укучыларның тормыш тәҗрибәсен, иҗат итү күнекмәләрен киңәйтү, кызыксынулары буенча иҗади эшчәнлеккә тарту. Иҗади омтылышларын һәм махсус, әдәби, иҗади сәләтләрен үстерү.

**Бурычлар:**

- Әдәби иҗат белән кызыксынуларын үстерү;
- Төрле жанрда иҗат итү күнекмәләре булдыру;
- Үзара ярдәмләшү, иҗат итү шатлыгы белән уртаклашу хисләре тәрбияләү.
- Иҗатка тартылган укучыларның әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен аңлап һәм хисси кабул итәргә өйрәтү.

Берләшмәгә төрле юнәлештә сәләтле булган, әдәби иҗатка омтылучы балалар кабул ителә. Иҗади тирәлек һәм уйлап, тиешле юнәлеш биреп алып барылучы җитәкчелек табигый талантлары булган, гомумән, иҗатка тартылган укучыларның нәтиҗәле үсеше өчен җирлек булып тора.

Әдәби иҗатка тарту ул укучыларны рухи, әхлакый яктан тәрбияләүдә үтемле чара, чөнки иҗат итү барышында кешенең тормышка карашы формалаша, ул үзенең урынын, яшәү мәгънәсен табарга омтыла.

Әдәби иҗат һәрвакыт үзара аралашу формасы да булып тора, шунлыктан иҗат итү барышында гражданлык һәм коллективизм хисләре тәрбияләнә.

***Икенче уку елы программасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:***

1. Яшь хәбәрчегә куелган таләпләрне үзләштерү, гамәли куллану;
2. Журналистикада жанрлар системасын аеру, төрле жанрда иҗат итү күнекмәләрен бирү;
3. Татар телендә чыгучы балалар матбугаты белән таныштыру;
4. Балалар өчен язучы журналистлар, әдипләр, шагыйрьләр иҗатын өйрәтү;
5. Журналистика, әдәбият, сәнгать әсәрләрен иҗади юнәлештә өйрәтү;
6. Иҗади уку күнекмәләрен үстерү;
7. Әдәби-иҗади күнегүләр аша, иҗади эшчәнлеккә тарту;
8. Чынбарлыкны иҗади кабул итү;
9. Әдәбият, сәнгать әсәрләрен иҗади якын килеп өйрәтү.

***Белем бирүнең икенче елында көтелгән нәтиҗәләр:***

1. Яшь хәбәрчегә куелган таләпләрне үзләштереп, төрле темага мәкаләләр язу; тема сайлау, мәгълүмат туплау, алган белемнәрне гамәли куллану.
2. Татар телендә чыгучы балалар матбугаты белән даими танышып барып, журналистикада жанрлар системасын аера белү, рубрикалар, газета төзелеше хакында башлангыч төшенчәләрне үзләштерү.
3. Төрле жанрда иҗат итә белү, башкаларның язмаларын редакцияләү күнекмәләрен үзләштерү.
4. Балалар өчен язучы журналистлар, әдипләр, шагыйрьләр иҗатын белү.
5. Иҗади уку күнекмәләренә ия булу. Төрле жанрдагы сәнгать әсәрләрен аера, хисси кабул итә белү.
6. Әдәби-иҗади күнегүләр үтәү.
7. ММЧның төрләрен аера белү, чагыштыру, үзенчәлекләрен күрү.

***Икенче ел азагында берләшмәгә йөрүчеләрдә тәрбияләнергә тиешле сыйфатлар:***

- Үзара ярдәмләшү, иҗади омтылыш, күмәк хезмәткә үз өлешеңне кертә белү.
- Яшь хәбәрчегә куелган сыйфатларны камилләштерү
- Әхлакый кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү
- Иҗади эшчәнлекне үстерү, вакытлы матбугатка карата кызыксыну формалаштыру.
- Тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын сурәтли белү, нәтиҗәләр чыгару.
- Мөстәкыйль рәвештә эш урынын әзерләү, оешытру, үзара ярдәмләшү.
- Дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә иҗади биремнәрне үтәү өчен максатчанлык.

**Икенче уку елына укыту-тематик планы**

| т/п № | Тема | Сәгать саны | Теория | Практика | Формы организации занятий | Контроль/ аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Тест<br>Иҗади эш |
| 2. | Журналистикада жанрлар төрлелеге | 94 | 55 | 39 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 3. | Текст белән эш | 56 | 26 | 30 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 4. | Шигърилекне тудыруда кайбер үзенчәлекләр | 30 | 18 | 12 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 5. | Сөйләм сәнгатендә сүз | 30 | 12 | 18 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Театрлы уен | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 6. | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 7. | Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| **Барысы** | | **216** | **114** | **102** | | |

**Икенче уку елы программасының эчтәлеге**

Икенче уку елында беренче елдагы белем һәм күнекмәләр тагын да тирәнәйтелде. Укучыларның эзләнү активлыкларын, иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән эш төрләре сайланды. Шулай ук төркемнәрдә эшләү, үзара хезмәттәшлек, иҗади тирәлек булдыруга зур игътибар бирелде. Теория белән практика үзара үрелеп, ныгытылып барды. Һәр яңа тема, төшенчә өйрәнелгәннән соң гамәли күнегүләр белән ныгытылды.

**1. Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре.**

2. **Журналистикада жанрлар төрлелеге:** интервью, репортаж жанрлары хакында мәгълүмат бирү, балалар матбугатында жанр төрлелеген күзәтү, анализлау; төрле жанрда иҗат итү күнекмәләре булдыру.
3. **Балалар матбугаты:** татар телендә чыгучы балалар матбугаты белән даими танышып бару, рубрикалар, бизәлеш, редколлегия эшчәнлеге хакында мәгълүматлы булу.
4. **Текст белән эш:** әдәби әсәрләрне хисси кабул итәргә әзерләү, якташ әдипләребез иҗатын өйрәнү, анализлау. Иҗат осталары белән очрашулар уздыру.
5. **Шигърилекне тудыруда кайбер үзенчәлекләр:** татар шигырь төзелеше турында белем һәм күнекмәләргә ия булу, иҗади сәләтне үстерердәй эш төрләре сайлау, акрошигырь язу техникасын өйрәнү; шагыйрьләр иҗатын күзәтү, хисси кабул итү, сәнгатьле сөйләм өстендә эшләү.
6. **Сөйләм сәнгатендә сүз:** сөйләм культурасы, хыял байлыгы тәрбияләүгә юнәлтелгән күнегүләр, үз сөйләмеңә таләпчән булу. Иҗади осталыкны, мавыгуны үстерердәй эш төрләре
7. **Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.**
8. **Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация**

## ӨЧЕНЧЕ УКУ ЕЛЫ

“Туган тел” әдәби-иҗат берләшмәсенең өченче уку елына **максаты**: үзләштерелгән белем-күнекмәләргә таянып, иҗади омтылышларын максатчан үстерү.

**Бурычлар:**

1. Укучыларны иҗатның мавыктыргыч төрләре белән таныштыруны дәвам итү.
2. Иҗади мавыктыру, өйрәнгән белем һәм күнекмәләрне тагын да тирәнәйтү. Барлык биремнәр дә укучыларның әдәби сәләтләрен үстерүгә юнәлтелә.
3. Әдәби белемнәрне киңәйтүгә һәм тирәнәйтү
4. Әдәбиятне, сәнгатьне иҗади кабул итүгә әзерләү.
5. Күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык, тирә-юньгә игътибар, иҗади күзаллау, үз-үзеңне тәрбияләү.

***Эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен түбәндәгеләр кулланыла:***

- Укучылар иҗат иткән материалларны әдәби эшкәртү.
- Тегеяки бу жанрга хас сыйфатларны якташ әдипләр иҗаты мисалында өйрәнү.
- Күмәк эшләр, уеннар, рольле уеннар, ситуатив уеннар һ.б.
- Әдәби иҗат берләшмәсенең гомуми эшчәнлек нәтиҗәләрен барлау, даими анализлау, редакцияләү.
- Мәдәният учакларында, китапханәләрдә берләшмәнең ачык утырышларын уздыру.
- Шәхси консультацияләр.
- Яшьтәшләре иҗат иткән язмаларны бергәләп күзәтү, эшкәртү, үзара киңәш мәктәбе булдыру.

***Белем бирүнең өченче елында көтелгән нәтиҗәләр:***

1. Чагыштыру, чагыштырып анализлау күнекмәләрен үстерү.
2. Тегеяки бу автор нинди максат куйган? Үз уйлаганын тормышка ашыру өчен нинди чаралардан файдаланган?
3. Жанр үзенчәлекләрен аера белү. Теманың әһәмиятен ачыклау. Бер үк теманы төрле авторлар ничек ачкан? Авторның башка телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләрен чагыштыру. Тәрҗемәдә авторның шәхси үзенчәлеге сакланганмы? Тәрҗемәдә тел-бизәкләү чаралары ничек кулланылган? Җөмлә төзелешендә нинди үзгәрешләр бар?
4. Стилистик анализ ясау күнекмәләрен үстерү.
5. Авторга хас стиль чараларын ачыклау. Төрле өзекләрнең авторын табу. Бирелгән өзекләрдән автор иҗатына хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләреңне мисаллар белән дәлилләү, исбатлый белү.

6. Шигырь төзелеше нигезләрен өйрәнеп, шагыйрьләр иҗатын анализлау.
7. Ритм, рифма турында мәгълүматлы булып, шигырь язу.
8. Татар телендә балалар өчен чыгучы тапшыруларны даими карап барып, үзбәя бирергә; тапшыруларда катнашырга; әдәби әсәрнең ТВда куелышы, үзенчәлекләре; әдәби әсәрне һәм сәхнәдә куелышының охшаш һәм аермалы якларын күрә белү.

**Өченче уку елына укыту-тематик планы**

| т/п № | Тема | Сәгать саны | Теория | Практика | Формы организации занятий | Формы контроля/ аттестации |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1.** | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | **2** | **1** | **1** | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Әңгәмә | Сораштыру<br>Тест<br>Иҗади эш |
| 2. | Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел | 48 | 21 | 27 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 3. | Сөйләм сәнгатендә сүз | 78 | 26 | 52 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 4. | Текст белән эш | 42 | 24 | 18 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 5. | Шигъри тәлгәшләр | 24 | 8 | 16 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку<br>Театрлы уен | Әңгәмә<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6. | Матур эшләребез бар | 18 | 8 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 7. | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 8. | Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| **Барысы** | | **216** | **90** | **126** | | |

**Өченче уку елы программасының эчтәлеге**

1. **Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре.**
2. **Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел:** халык авыз иҗаты әсәрләрендә, шигырьләрдә төшеп калган сүзләрне таба белү; теге яки бу әсәр герое исеменнән әсәрдә булмаган вакыйганы уйлап чыгарып сөйләү (хыял ярдәмендә иҗат итү.)

3. **Сөйләм сәнгатендә сүз:** әсәр героен башка шартларга куеп сурәтләү; әсәр героен үткәннән киләчәккә, яки киресенчә бүгенгедән үткәнгә куеп сурәтләү. Әсәр эчтәлеген теге яки бу герой исеменнән сөйләргә. Берләшмә утырышында авторларның иҗат җимешләрен иҗади күзаллап укырга. Авторга, әсәрнең героена хас сыйфатларны күрсәтә белергә. Кемнең сөйләме күбрәк ошаганны, аның сәбәпләрен аңлатырга. Татар телендәге балалар өчен телевизион тапшыруларга кызыксыну уяту.
4. **Текст белән эш:** әдәби деталь аңлатмасын тирәнәйтү, төрле типтагы текстлардан әдәби детальләрне табу, анализлау, геройның теге яки бу сыйфатын сурәтләүче әдәби детальләрне таба белү. Анализлау һәм әдәби әсәргә, иҗатка бәя бирү күнекмәләре булдыру. Тукай шигырьләреннән татарча мультфильмнарны анализларга. Бәяләмә, рецензия, отзыв язарга өйрәтү.
5. **Шигъри тәлгәшләр:** төрле шагыйрьләр иҗатыннан рифма төрләрен таба белү, төрле шагыйрьләр иҗатына охшатып шигырьләр язу, дәвам итү, үз версияңне тәкъдим итү, әсәрдән үзеңә ошаган урынны билгеләргә һәм аңлата белергә, бер үк әсәргә аннотация һәм рецензия язу. Аннотация һәм рецензиянең аермалы якларын күрсәтә белү. Китап укуга, әдәбияткә, шигърияткә, балалар өчен чыгучы татарча тапшыруларга кызыксыну уяту. Гражданлык, патриотизм хисләре тәрбияләү.
6. **Матур эшләребез бар** Дусларын, туганнарын үзләренең әсәрләре белән куандыру. Якташ әдипләребез циклы буенча иҗади эзләнү эшләре язу. Дәрвишләр бистәсендә яшәп иҗат иткән шәхесләрне барлау. “Туган тел” берләшмәсенең иҗади басмасын, иҗади эшләр туплап китап чыгару. Тырышлык, пөхтәлек, хыял, эстетик матурлыкны күрү кебек сыйфатларны үзеңдә булдыру.
7. **Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.**
8. **Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация**

## ДҮРТЕНЧЕ УКУ ЕЛЫ

Уйлаган фикереңне матур һәм дөрес итеп башкаларга җиткерә белү - милли культураның бер өлеше. Укучыларның язма һәм телдән сөйләмен үстерү, аларда газета, радио, телевидение теленә карата дөрес мөнәсәбәт формалаштыру балаларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт-мөмкинлекләренә уңай тәэсир итәрлек итеп оештырылырга тиеш. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, ана телебезгә кызыксыну уятырга ярдәм итә.

Газета хәбәрчесе булу - журналистикага беренче адым ясау дигән сүз. Ә кем соң ул газета – журналлар хәбәрчесе? Аңа нинди сыйфатлар хас? Хәбәрче тирән белемле, күп мәгълүматлы, үткен һәм җор телле булырга тиеш.

***Дүртенче уку елының максаты:***

Журналист һөнәренең серләренә төшендерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләре белән таныштыру; эзләнүчән шәхес формалаштыру.

***Бурычлары:***

- вакытлы матбугать жанрлары, аның төрләре белән таныштыру;
- газета чыгаруда иң кирәкле булган: тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү серләренә төшендерү;
- газета теле үзенчәлекләрен өйрәтү;
- газета-журналлар басу технологиясе турында мәгълүмат бирү;
- укучының газета жанрларына караган материалларны дөрес итеп язарга өйрәнүләренә ирешү;
- балаларның фикерләү сәләтләрен үстерү, иҗат активлыкларын киңәйтү;
- эстетик зәвык тәрбияләү.

***Эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен түбәндәгеләр кулланыла:***

- Укучылар иҗат иткән материалларны әдәби эшкәртү.
- Теге яки бу жанрга хас сыйфатларны якташ әдипләр иҗаты мисалында өйрәнү.

- Әдәби иҗат берләшмәсенең гомуми эшчәнлек нәтиҗәләрен барлау, даими анализлау, редакцияләү.
- Берләшмәнең ачык утырышларын уздыру.
- Шәхси консультацияләр.
- Яшьтәшләре иҗат иткән язмаларны бергәләп күзәтү, эшкәртү, үзара киңәш мәктәбе булдыру.

***Дүртенче уку елында көтелгән нәтиҗә.*** Журналист һөнәренең серләрен үзләштерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләрен аңлау, иҗат эшенә тартылу.

**Дүртенче уку елына укыту-тематик планы**

| т/п № | Тема | Барлыгы | Теория | Практика | Формы организации занятий | Контроль/ аттестация |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1.** | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 2. | Журналистика жанрлары | 44 | 26 | 18 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 3. | Публицистик жанрлар | 34 | 16 | 18 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 4. | Проза | 32 | 16 | 16 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Театрлы уен | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 5. | Экскурсияләр. Очрашулар. Кичәләр. | 24 | 8 | 16 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6. | Кичәләр. Конкурслар | 18 | 7 | 11 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 7. | Газета чыгару | 34 | 14 | 20 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 8. | Журналистикада аналитик жанрлар | 24 | 14 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку<br>Театрлы | Әңгәмә<br>Иҗади эш<br>Тест |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | уен | |
| 9. | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү Күзәтү | Сораштыру Иҗади эш Тест |
| | Программаны үзләштерү аттестациясе | 2 | 1 | 1 | Эзләнү Күзәтү | Тест Тест |
| | **Барысы** | 216 | 104 | 112 | | |

1. Кереш дәрес. Кабатлау

Бу уку елында катлаулыга барып, журналистика жанрларын өйрәнүне дәвам итү.

2. Аналитик жанрлар. Хәбәри жанрлар вакыйгаларны үз вакытында яктыру белән чикләнә. Ләкин күп кенә очракта укучы яңалык алу белән генә канәгатьләнми. Факт һәм вакыйганың асылына төшенер ә, тормыштагы кайбер күренешләрнең сәбәпләрен белергә тели. Монда хәбәрче-журналист аналитик жанр куллана. Аналитик жанрлар:

А) Корреспонденция вакыйгаларга, куренешләргә булдыра алганча анализ ясап, сәбәпләрен ачарга тырышып языла. Конкрет бер мәсьәләгә туктала, урынга барып, мәсьәләне тикшерә, сәбәпләрен ачыклый, киләчәкне күзаллый. Күп вакыт сарыф ителә.

Б) Мәкалә. Корреспонденциягә охшаш, әмма киңрәк колачта, төрле мәсьәләләрдән чыгып гомумиләштерүләр ясала, анализ тагын да тирән ясап языла. Монда инде журналист үз фикерен әйтә, чагыштырулар ясый, мәсьәләләрне чишү юлларын да тәкъдим итә. Мәкалә күп материал туплап, аларны өйрәнеп, вакыт һәм хезмәт куеп языла.

Укучыларга кимчелекләрне курсәтергә, киңәшләр бирергә. Уңышлы язылган материалны вакытлы матбугатка тәкъдим итәргә.

3. Проза әсәрләре. Хикәяләр ничек языла. Тәмамланган уйны белдереп, вакыйга бер генә туры сызык буенча үстерелә. Композиция һәм сюжет. Балалар язган хикәяләрне анализлау. Парча- тормыштагы күренешләргә тирәнтен бәя биреп язылган прозаик әсәр.

4. Драма - эпик әсәр, персонажлар сәхнәдә мөстәкыйль чыгыш ясыйлар, тамашачы үзе анализ ясый. Комедия, трагедия. Аңлатма бирү. Балаларга скетч, пьеса яздырып карау.

5. Уку елы барышында журналистлар, язучылар, әдәби эшлеклеләр белән очрашулар, кичәләр оештырыла. Музейларга экскурсияләр ( Арчадагы “Әлифба”, Күлле-Киме авылындагы Сибгать Хәким, Күәм авылындагы Самат Шакир музейларына).

6. Район һәм республика күләмендә оештырылган иҗади конкурсларда катнашу.

7. Айга 1 тапкыр компьютер аша җыйнап әдәби берләшмәнең иҗади органы “Хыял” газетасын чыгару.

8. Журналист һәм укучы арасындагы бәйләнеш турында түгәрәк өстәл артында сөйләшү.

9. Йомгаклау дәресе “Алтын каләм” - фестиваль формасында уздырыла. Әсәр яклау.

10. **Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.**

11. **Программаны үзләштерү аттестациясе**

## Программаны үтәүдә педагогик-оештыру шартлары

**-Укыту кабинете**
**-Парталар, урындыклар**
**-ИКТ** (компьютер, принтер, интерактив такта, электрон текстлар)
-Электрон таблицалар
-

## Аттестация/контроль формасы һәм бәяләү материалы

- кереш психологик-педагогик диагностика
- агымдагы диагностика
- арадаш аттестация
- йомгаклау аттестациясе

**бәяләү материалы**

-- тестлар
- әңгәмә сораулары
- анкета
- дидактик материаллар

-иҗади эшләр

## Әдәбият исемлеге
## Норматив документлар:


- Указ Президента Российской Федерации от 7 мая 2018 г. № 204 «О национальных целях и стратегических задачах развития Российской Федерации на период до 2024 года».
- Указ Президента Российской Федерации от 29 мая 2017 г. № 240 «Об объявлении в Российской Федерации Десятилетия детства».
- Федеральный закон РФ 273-ФЭ «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 г.
- Постановление Правительства Российской Федерации от 31 октября 2018 г. № 1288 «Об организации проектной деятельности в Правительстве Российской Федерации».
- Распоряжение Правительства Российской Федерации от 6 июля 2018 г. N 1375, об утверждении Плана основных мероприятий до 2020 года, проводимых в рамках Десятилетия детства.
- Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 09 ноября 2018 N 196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам».
- Приказ Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 5 мая 2018 г. N 298 н «Об утверждении профессионального стандарта "Педагог дополнительного образования детей и взрослых».
- Стратегия инновационного развития Российской Федерации на период до 2020 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 8 декабря 2011 г. № 2227-р.
- Федеральная целевая программа развития образования на 2016-2020 годы, утвержденная Постановлением Правительства Российской Федерации от 23 мая 2015 г. № 497.
- Концепция развития дополнительного образования детей, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 4 сентября 2014 г. № 1726-р.
- Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 29 мая 2015 г. № 996-р.

- Концепция общенациональной системы выявления и развития молодых талантов на 2015-2020 годы (утверждена Президентом Российской Федерации 3 апреля 2012 г. № Пр-827) и комплекс мер по ее реализации (утвержден Правительством Российской Федерации 27 мая 2015 г. № 3274п- П8).
- Стратегическая инициатива "Новая модель системы дополнительного образования", одобренная Президентом Российской Федерации 27 мая 2015 г.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге:**


1. Әсәдуллин А.Ш. Татар сөйләме / А.Ш.Әсәдуллин. – Казан: Тарих,2002.- 256 б.
2. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнүреш йолалары. Казан тат.кит.кәшр., 1995.
3. Гарифуллин В.З. Журналистның ижади эшчәнлеге, В.З.Гарифуллин. — Казан: КДУГ. 2004.— 156 6
4. Гарифуллин В.З. Язар сүзең булса... – Казан, 2000. – 204 б.
5. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. - 144 б.
6. Габдулхаков В.Ф. Риторика. – Казань, Магариф, 2004
7. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. Казан: Мәгариф нәшр. 2005
8. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: Мәкальләр җыелмасы:3 томда/ 2 нче басма. – Казан, 2010.
9. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. - –азан, 1984.
10. Казан театрлары. Альбом. К., 2011.
11. “Мәгариф” журналы.
12. “Сабантуй” газетасы..
13. “Ялкын” журналы
14. Н.Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 2003.
15. Мияссарова И.Х., Гарифуллина Ф.Ш., Гильфанова Ә.Ә. “Кем тизрәк, өлгеррәк”, укытучылар, ата-аналар һәм урта педагогик уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы,. – Казан,2010
16. Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге – Казан: Мәгариф, 2009. – 199 б.
17. Спирина Н.А. Журналистика в школе: программа, материалы к занятиям. – Волгоград: Учитель, 2011.-207 б.
18. Галләмова Р. Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, сынамышлар. – Казан: Гыйлем, 2014. – 80 б.
19. Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Конференция (Казан, 17 май, 2005 ел) материаллары: докладлар һәм тезислар. – Казан: ун-тет нәшр., 2005. – 144
20. ММЧ хокукларын яклау сайты. URL: http://www.mmdc.ru/
21. "Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе сайты. URL: http://www.tat.tnv.ru

Әйдәгез, үләннәрне ____________________ , чәчәкләрне ________________, елгаларны ___________________ , күбәләкләрне ___________________ , куакларны __________________ .

В-14. Репликаларны сөйләшү тәртибе буенча күрсәтегез.

______ - Әлбәттә, юк. Шуңа күрә походка һәр кеше йөри алмый. Утсыз, җылы сусыз яшәргә өйрәнмәгән кешеләргә урманда палаткаларда җиңел булмый.

______ - Ә сез урманда вакытны ничек үткәрәсез? Биш көн дәвамында нишлисез? Анда бит телевизор да, компьютер да юк.

______ - Камил, син уку елы тәмамлангач кая барырга җыенасың?

______ - Урманны чистартабыз, төрле уеннар уйныйбыз, ашарга да чиратлап үзебез пешерәбез. Биш көн бик тиз һәм сизелмичә дә үтә.

______ - Юк, рәхмәт. Мин походка йөрергә яратмыйм. Анда шәһәр уңайлыклары юк.

______ - Без классыбыз белән биш көнлек походка барабыз. Безнең белән барырга теләгең юкмы?

С-15. Шигырьне укыгыз. Эчтәлеген языгыз.

Кондызлы күл

Чалкан ятып, суларда
Йөзә кондыз баласы.
Тын тугайда сокланып
Карап тора анасы.

Кондыз, кондыз,
Сак бул көндез.
Кешеләр бит
Бигрәк кансыз.

Аучы килсә,
Атса юньсез,
Әткәң-әнкәң
Нишләр синсез?

Тын күлдә йөзү рәхәт:
Батасы да калкасы.
Оядан башын чыгарып,
Саклап тора атасы.

Рәшит Бәшәр

**чалкан ятып** - лежа на спине
**кондыз баласы** - бобрёнок
**атса** - если застрелит
**батасы да калкасы** - надо нырять и выныривать

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

## Модуль дистанционного обучения.

1. **Пояснительная записка.**

Одним из основных направлений современной школы и системы дополнительного образования – усиление воспитывающей функции всего учебно-воспитательного процесса, дальнейшее обновление содержания, форм, методов обучения и воспитания в соответствии с поставленными целями и задачами.

Программа литературно-творческого объеденения «Туган тел» модифицированная, по направленности – художественно-эстетическая, по форме организации – многопрофильная, по цели обучения - познавательная, воспитательная и развивающая.

**Данная образовательная** программа актуальна и востребована, так как именно в творческом коллективе успешно происходит преодоление закомплексованности ребенка и ориентирована на всестороннее развитие личности, его неповторимой индивидуальности. Тематические творческие занятия выполняют одновременно познавательную, воспитательную и развивающую функции.

Данная программа создана в условиях пандемии.

В обучении важен результат – экономически целесообразный, оправдывающий все ресурсы, затраченные этот процесс.

Дистанционные проекты способствуют развитию творчества, инициативности, помогают осознать, сравнить свои собственные умения со способностями коллег. При этом среда дистанционных форм обеспечивает интенсивный образовательный рост, в некоторых случаях в условиях "повышенной сложности".

Дистанционное обучение - одна из важнейших составляющих современной образовательной среды. Без изменения форм учебной деятельности, а может быть и структуры учебного процесса – работа сетевого педагога будет не эффективна.

И учителю не следует этого бояться, а нужно понять, что мир современного ученика ограничить пространством парты, доски и мела сегодня просто невозможно! Усадить за компьютер, для прохождения какого либо теста, уже не актуально.... На мой взгляд, миссия педагога и состоит в том, чтобы разработать сообразно запросам времени учебные программы, создать учебные материалы для организации образовательной деятельности, основанной на самостоятельности выбора решения, творческой реализации поставленных целей, направленной на развитие индивидуальности мышления ученика.